**Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы**
**Югары Чура авыл җирлеге Башлыгы**
**КАРАРЫ**

**13 ноябрь 2020 ел** **№3**

**«Кукмара муниципаль районы Югары Чура авыл җирлегенең Кече Чура авылы торак пунктында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыены үткәрүне билгеләү турында»**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы һәм Кукмара муниципаль районы Югары Чура авыл җирлеге Уставының 22 статьясы нигезендә карар бирәм:

1. 2020 елның 25 ноябрендә 14 сәгать 00 минутка Кукмара муниципаль районының Кече Чура авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының беренче этабын билгеләргә.

2. 2020 елның 25 ноябрендә 15 сәгать 00 минутка Кукмара муниципаль районының Кече Чүра авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча халык җыенының икенче этабын билгеләргә.

3 Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга «Көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлар, гомуми белем бирү мәктәпләрендә укучылар, I төркем инвалидлары, Бөек Ватан сугышында катнашучылар, 80 яшьтәге һәм аннан өлкәнрәк яшьтәге пенсионерлардан кала, Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Югары Чура авыл җирлегенең Кече Чура авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр яшәүчедән 2021 елда үзара салымны 500 сум күләмендә кертергә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен юнәлтүгә сез ризамы:

-Кече Чура авылы Зеленая урамындагы юлларны вак таш түшәү (сатып алу, күчереп йөртү, вак таш салу) җайланмасы; проект-смета документациясен эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру;

-Кече Чура авылы Мәктәп урамындагы вак таш өслекле юлларны ямау; проект-смета документациясен эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру;

-Кече Чура авылында энергия саклаучы лампалар, светодиод яктырткычлар, махсус җиһазлар сатып алу, урнаштыру махсус җайланмаларны сатып алу, урам яктырткычлары, яктырткычлар урнаштыру;

-Кече Чура авылы Мәктәп урамындагы юл билгеләре сатып алу;

-Кече Чура авылы зираты янындагы автомобиль күперен ремонтлау; проект-смета документациясен эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру;

-Кече Чура авылында Зеленая урамындагы җәяүлеләр күперен ремонтлау; проект-смета документациясен эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру;

- Кече Чура авылындагы зиратны киртәләү өчен материал сатып алу;

-Кече Чура авылында юлларны кардан чистарту, проект-смета документациясен эшләү;

-Кече Чура авылы урамнарында коры агачларны һәм куакларны кисү,  санитар эшкәртү; махсус техника табу; проект-смета документациясен эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру;

-Кече Чура авылында видеокамералар сатып алу һәм урнаштыру.

«РИЗА» «КАРШЫ»

5. Гражданнар җыенын үткәрү өчен торак пунктта яшәүчеләрнең исемлеген территориаль билге буенча (урамнар буенча) бүләргә.

6. Гражданнар җыенын оештыручы итеп, Югары Чура авылы Башкарма комитетын билгеләргә.

7. Әлеге карарны кабул ителгән көннән соң 5 көн эчендә мәгълүмат стендларында һәм Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында «Авыл җирлекләре» бүлегендә урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә.

8. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Югары Чура авыл җирлеге башлыгы: И. Н.Алексеев